| | |
|---|---|
| **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ** | **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН** |
| ***БУА ШӘҺӘРЕ*** | ***ГЛАВА*** |
| ***БУА*** | ***ГОРОДА БУИНСКА*** |
| ***МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ*** | ***БУИНСКОГО*** |
| ***БАШЛЫГЫ*** | ***МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА*** |

# КАРАР

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ

14.07.2026 № 7

Буа шәһәре» муниципаль берәмлеге чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар уздыру турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль берәмлекләренең чикләрен үзгәртү турында» Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советының 2026 елның 10 июлендәге 1-15 номерлы карары нигезендә, «Буа шәһәре» муниципаль берәмлеге халкының гавами тыңлаулар уздыру юлы белән «Буа шәһәре» муниципаль берәмлеге чикләрен үзгәртү турындагы мәсьәләне тикшерүдә катнашу хокукларын үтәү максатларында карар бирәм:

1. Карлы авыл җирлеге җир кишәрлекләрен «Буа шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясе составына кертү юлы белән «Буа шәһәре» муниципаль берәмлеге чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча 2026 елның июлендә 10:00 сәгатькә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитеты бинасында Татарстан Республикасы, Буа ш., Жорес ур., 110а йорт, 2 кат, (утырыш залы) адресы буенча гавами тыңлаулар уздыруны билгеләргә.
2. Гавами тыңлауларда карала торган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр түбәндәге адрес буенча 2026 елның «24» июленә кадәр кабул ителә: Буа шәһәре Космовский урамы, 91Б йорт, Буа муниципаль районы Башкарма комитеты, телефон +7(84374) 3-30-84.

3. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән мәсьәлә буенча гавами тыңлауларны әзерләү һәм уздыру буенча эш төркеме составын расларга (2 нче кушымта).

4. Әлеге карар Буа шәһәренең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан ителергә тиеш:

- ТР, Буа ш., Жорес ур., 110А йорт (Буа муниципаль районы Башкарма комитеты бинасы);

- ТР, Буа шәһәре, Космовский ур., 91Б йорт (Буа шәһәре Башкарма комитеты бинасы);

- ТР, Буа шәһәре, Р. Люксембург ур., 157 йорт (район мәдәният йорты бинасы);

- ТР, Буа шәһәре, Төзелеш ур., 4 йорт («Сахарник» клубы бинасы).

5. Әлеге карар Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча рәсми басылып чыккан көннән законлы көченә керә: http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук «Буа шәһәре» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында http://buinsk.tatarstan.ru. адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль районының
Буа шәһәре башлыгы Р.Р. Камартдинов

Татарстан Республикасы Буа муниципаль
районының Буа шәһәре башлыгының
______ 2026 елгы карарына 1 нче кушымта

Үзгәрешләрне исәпкә алып,

муниципаль берәмлекләр чикләренең

**Карта-схемасы**

